Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы

карары

2021 елның17 ноябре №54

**«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 27 ноябренә 09 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында, И. Хәйретдинов урамы, 54 нче йортта үткәрергә билгеләргә.

2. 2021 елның 27 ноябренә 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында, И. Хәйретдинов урамы, 54 нче йортта үткәрергә билгеләргә.

3. 2021 елның 27 ноябренә 11 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында, И. Хәйретдинов урамы, 54 нче йортта үткәрергә билгеләргә.

4. 2021 елның 27 ноябренә 12 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылында, И. Хәйретдинов урамы, 54 нче йортта үткәрергә билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Янсыбы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 1000 сум

күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

1. Юлларга вак таш җәю, юлларга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.
2. Янсыбы авылы юлларын кардан чистарту.
3. Янсыбы авылында чишмәләрне ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү
4. Урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру.
5. Балалар уен мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.
6. Артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру.
7. Янсыбы авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Зур Кукмара авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

8. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев